**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КЕЧЕ ШИЛНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«14» февраль 2023 ел №42

Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 5 өлеше, «Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ Федераль закон нигезендә Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибен кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://www. pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет Җитәкчесе А.Г. Даутов

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының 2023 елның 14 февраль 42 номерлы карарына кушымта

## Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану тәртибе

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану тәртибе (алга таба – Тәртип) Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә урнашкан һәм җирләрдән файдалануның махсус шартлары булган зоналар булып торган җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын һәм юл буе полосаларын билгеләү һәм куллану шартларын регламентлый.

1.2. Әлеге Тәртип Кече Шилнә авыл җирлегенең җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм юл буе полосалары чикләрендә юл эшләрен алып баручы яки башка эшчәнлекне гамәлгә ашыручы юридик һәм физик затлар тарафыннан башкару өчен мәҗбүри булып тора.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төшенчәләр һәм терминнар «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон белән билгеләнгән мәгънәдә кулланыла.

### 2. Җирле билгеләнештәге автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларын билгеләү һәм файдалану

2.1. Җирле билгеләнештәге автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасы чикләре территорияне планлаштыру буенча документлар нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган автомобиль юлларын һәм (яки) юл сервисы объектларын урнаштыру өчен җир бүлеп бирү нормаларын исәпкә алып билгеләнә.

2.2. Җирле билгеләнештәге автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасын тәшкил иткән җир кишәрлекләренә хокуклар алу һәм туктату, күрсәтелгән җир кишәрлекләрен тиешле җир категориясенә кертү гражданнар, җир законнары, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 8 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба текст буенча – 2007 елның 8 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль закон), муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә ашырыла.

2.3. Җирле билгеләнештәге автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасын тәшкил иткән формалаштырылган җир кишәрлекләре билгеләнгән тәртиптә дәүләт кадастр исәбенә куелырга тиеш.

2.4. Автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасы чикләрендә, 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан тыш, тыела:

- автомобиль юлын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту, шулай ук юл сервисы объектларын урнаштыру белән бәйле булмаган эшләрне башкару;

- автомобиль юлына хезмәт күрсәтү, аны төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау, ремонтлау һәм карап тоту өчен каралмаган һәм юл сервисы объектларына кермәгән биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне һәм башка объектларны урнаштыру;

- җир кишәрлекләрен сукалау, үлән чабу, урман үсентеләрен һәм башка күпьеллык үсентеләрне кисү һәм аларга зыян китерү, торф чыгару һәм туфракны казу, автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасын карап тоту яки автомобиль юлларын, аның участокларын ремонтлау эшләреннән тыш;

- мал көтү, шулай ук автомобиль юллары хуҗалары белән килешенгән махсус урыннардан читтә аларны автомобиль юллары аша чыгару;

- техник регламентларның һәм (яки) юл хәрәкәте иминлеге турында норматив хокукый актларның таләпләренә туры килми торган реклама конструкцияләрен урнаштыру;

- юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итүгә яки юл эшчәнлеген тормышка ашыруга катнашы булмаган мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләре урнаштыру.

2.5. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендәге җир кишәрлекләренә карата сервитутны билгеләү граждannar законнары һәм җир законнары белән билгеләнгән тәртиптә 2007 елның 8 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясында каралган үзенчәлекләрне исәпкә алып билгеләнә.

2.6. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә юл сервисы объектларын урнаштыру территорияне планлаштыру буенча документлар һәм техник регламентлар таләпләре нигезендә башкарыла.

2.7. Автомобиль юлларын юл сервисы объектлары белән тәэмин итү түбәндәге шартлар үтәлгәндә башкарылырга тиеш:

- юл сервисы объектлары автомобиль юлларында күрү мөмкинлеген, юл хәрәкәте иминлегенең башка шартларын, шулай ук автомобиль юлларын һәм аларда урнашкан корылмаларны һәм башка объектларны куллану һәм карап тоту шартларын начарайтырга тиеш түгел;

- юл сервисы объектларын урнаштыру урынын сайлау планлаштырылган автомобиль юлларын төзүне, реконструкцияләүне, капиталь ремонтлауны исәпкә алып башкарылырга тиеш;

- юл сервисы объектлары транспорт чаралары тукталышлары һәм тукталу урыннары, шулай ук автомобиль юлларыннан анда керүне тәэмин итү максатында, килү юллары, төшү юллары һәм тоташу урыннары белән җиһазланырга тиеш. Автомобиль юлларына тоташканда, килү һәм төшү юллары күчеш-тизләтелгән полосалар белән җиһазланырга һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү максатында, автомобиль юлларын төзекләндерү элементлары белән җиһазланырга тиеш.

2.8. Юл сервисы объекты җирле билнеләнештәге автомобиль юлына тоташканда, мондый автомобиль юлы хуҗасы тоташа торган объектларның милекчеләренә (хуҗаларына) автомобиль юлларын планлаштырылган реконструкцияләү, капиталь ремонтлау һәм мондый реконструкцияләү, капиталь ремонтлау сроклары турында хәбәр итә.

2.9. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә урнашырга мөмкин:

- инженерлык коммуникацияләре, тимер юллар, электр тапшыру линияләре, элемтә линияләре, торба үткәргеч һәм тимер юл транспорты объектлары, шулай ук автомобиль юллары буенда урнашкан яки аларны кисеп үтүче башка корылмалар һәм объектлар;

- автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосаларыннан читтә урнашкан һәм аларга керүне таләп итүче объектларга керү, төшү юллары һәм тоташу юллары (күчеш-тизләтелгән полосаларны да кертеп).

## 3. Юл буе полосаларын билгеләү һәм файдалану

3.1. Автомобиль юллары өчен, торак пунктлар чикләрендә урнашкан автомобиль юлларыннан тыш, юл буе полосалары билгеләнә.

3.2. Юл буе полосалары чикләрендәге җир кишәрлекләре милекчеләрдән, хуҗалардан, кулланучылардан һәм арендаторлардан алынмый.

3.3. Һәр юл буе полосасының киңлеге җирле билгеләнештәге юлларның бүлеп бирелгән полосасы чикләреннән исәпләнә башлый һәм автомобиль юлларының классына һәм (яки) категориясенә карап, аларның үсеш перспективаларын исәпкә алып түбәндәге размерда билгеләнә:

1) илле метр – дүртенче категорияле автомобиль юллары өчен;

2) егерме биш метр – бишенче категорияле автомобиль юллары өчен.

3.4. Юл буе полосалары урнашкан җирләр Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең территориаль органнарында билгеләнгән тәртиптә исәпкә алынырга тиеш.

3.5. Җирле билгеләнештәге автомобиль юллары полосаларын билгеләү турында карар Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан кабул ителә.

3.6. Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты, юл буе полосалары чикләрен билгеләү яки юл буе полосалары чикләрен үзгәртү турында карар кабул итеп, җирлектә юл буе полосалары чикләрен билгеләүне башкара. Шулай ук әлеге карар кабул ителгәннән соң җиде көн эчендә карар күчермәсен Тукай муниципаль районы Башкарма комитетына җибәрә, шулай ук юл буе полосалары чикләрен билгеләү турында карар чыгарылган көннән бер ай эчендә юл буе полосалары чикләрендәге җир кишәрлекләренең милекчеләренә, җирдән файдаланучыларга, җир хуҗаларына һәм арендачыларга җир кишәрлекләреннән файдалануның махсус режимы турында хәбәр итә.

3.7. Автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектларын, юл эшчәнлеген башкару өчен билгеләнгән объектларны, юл сервисы объектларын һәм башка объектларны төзү, реклама конструкцияләре, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләре урнаштыру Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты ризалыгы булган очракта рөхсәт ителә.

Әлеге ризалык автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә мондый объектлар төзүне, реконструкцияләүне, реклама конструкцияләре, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләр куюны гамәлгә ашыручы затлар тарафыннан үтәлүе мәҗбүри булган таләпләр һәм шартларны үз эченә алырга тиеш.

3.8. Автомобиль юлларының юл буе полосалары чикләрендә капиталь төзелеш объектларын, юл эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән объектларны, юл сервисы объектларын төзүне, реконструкцияләүне, реклама конструкцияләре, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләр куюны төзелешкә рөхсәтсез (күрсәтелгән объектларны төзү яисә реконструкцияләү өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителгән очракта), әлеге Тәртипнең 3.7 пунктында каралган ризалыксыз яки үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләрне һәм шартларны бозып гамәлгә ашыручы затлар дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган һәм (яисә) автомобиль юллары хуҗалары таләбе буенча капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне, реклама конструкцияләре, мәгълүмат такталары һәм күрсәткечләр куюны туктатырга, законсыз корылган объектларны сүтәргә һәм автомобиль юлларын башлангыч халәткә китерергә тиеш.

Мондый таләпләрне үтәүдән баш тарткан очракта, автомобиль юллары хуҗалары, Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге объектларны, корылмаларны законсыз торгызуда гаепле затлар исәбенә, әлеге эшләрне башкаруга киткән чыгымнарны компенсацияләү белән, төзелгән объектларны яки корылмаларны бетерү эшләрен башкара.

## 4. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү һәм үзгәртеп кору

4.1. Автомобиль юлының бүлеп бирелгән полоса чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү, үзгәртеп кору мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан алар хисабына, инженерлык коммуникацияләре хуҗаларының автомобиль юлы хуҗасы белән төзелә торган шартнамә һәм Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы һәм "Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында" 2007 елның 8 ноябрендәге Федераль закон нигезендә бирелә торган төзелешкә рөхсәт нигезендә гамәлгә ашырыла (мондый инженерлык коммуникацияләрен салу яки үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителгән очракта).

4.2. Автомобиль юлларының бүлеп бирелгән полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яки үзгәртеп коруны мондый инженерлык коммуникацияләр хуҗалары тарафыннан яки алар хисабына проектлаганда, автомобиль юллары хуҗалары мондый инженерлык коммуникацияләрен урнаштыруны язмача килештерәләр.

4.3. Автомобиль юлының юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү, үзгәртеп кору мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан яки алар хисабына автомобиль юлы хуҗасының язма формада ризалыгы булганда башкарыла. Бу ризалыкта мондый инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан аларны салганда, күчергәндә,

үзгәртеп корганда мәҗбүри үтәлергә тиешле техник таләпләр һәм шартлар булырга тиеш.

4.4. Автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосалары яки юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләре салынган, күчерелгән яки үзгәртеп корылган очракта, төзелешкә рөхсәт Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты тарафыннан бирелә.

4.5. Автомобиль юлының бүлеп бирелгән полосасы һәм (яки) юл буе полосалары чикләрендә инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яки үзгәртеп кору автомобиль юлын, аның участокларын реконструкцияләүгә яки капиталь ремонтлауга китергән очракта, мондый реконструкция, капиталь ремонт инженерлык коммуникацияләре хуҗалары тарафыннан яисә алар хисабына башкарыла.

4.6. Әлеге Тәртибнең 4.2 һәм 4.3 пунктларында каралган ризалыксыз һәм төзелешкә рөхсәтсез (мондый инженерлык коммуникацияләрен салу, күчерү яисә үзгәртеп кору өчен төзелешкә рөхсәт бирү таләп ителгән очракта) яки үтәлүе мәҗбүри булган техник таләпләрне һәм шартларны бозып, аларны салуны, күчерүне яисә яңадан урнаштыруны гамәлгә ашыручы инженерлык коммуникацияләре хуҗалары дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган һәм (яисә) автомобиль юлы хуҗасы таләбе буенча инженерлык коммуникацияләрен салуны, күчерүне яисә яңадан урнаштыруны туктатырга, законсыз корылган корылмаларны, башка объектларны сүтәргә һәм автомобиль юлын башлангыч халәтенә китерергә тиеш.

Күрсәтелгән таләпләрне үтәүдән баш тарткан очракта, автомобиль юлы хуҗасы, Россия Федерациясе законнары нигезендә, законсыз рәвештә мондый корылмаларны, башка объектларны күчерүдә яки үзгәртеп коруда гаепле затлар исәбенә, салынган яки үзгәртеп корылган инженерлык коммуникацияләрен бетерү буенча эшләр башкара.

## 5. Җаваплылык

5.1. Бүлеп бирелгән полосаларда яки юл буе полосалары чикләрендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары, төзелеш нормалары һәм кагыйдәләре, шулай ук әлеге Тәртип таләпләрен бозып төзелгән юл сервисы һәм реклама объектлары, башка объектлар Гражданнар кодексының 222 статьясы нигезендә рөхсәтсез төзелеш дип таныла.

Хокукый режим һәм рөхсәтсез төзелгән корылманы сүтү тәртибе Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә билгеләнә.

5.2. Әлеге объектларның милекчеләре һәм хуҗалары, әгәр объектлар автомобиль юлларын ремонтлаганда, реконструкцияләгәндә аны нормаль эксплуатацияләү өчен каршылыклар тудырган яки аның буенча хәрәкәт шартларын начарайткан очракта, аларны үз хисабына сүтәргә яки күчерергә тиеш.

5.3. Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты үз компетенциясе чикләрендә бүлеп бирелгән полосалар һәм юл буе полосалары чикләрендә, шул исәптән гадәттән тыш хәлләрне кисәтү яки аларның нәтиҗәләрен бетерү өчен, җирләрне куллануны контрольдә тотарга тиеш.

5.4. Әлеге Тәртип таләпләрен бозуда гаепле юридик һәм физик затлар Россия Федерациясенең гамәлдәге законнары нигезендә җаваплылыкка ия.